# БУЫННАРДАН-БУЫННАРГА КҮЧӘ БАТЫРЛАРНЫҢ ГОМЕРЕ ҖЫР БУЛЫП

(1812 елгы Ватан сугышының 200 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль монтаж)

**Лидия КОНСТАНТИНОВА, Мамадыш районы Үсәли урта мәктәбенең тарих укытучысы**

**Максат.** Укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирү, бердәмлектә — көч икәнлеген күрсәтү, илебезнең данлы үткәне белән горурлану хисе уяту, 1812 елгы канлы вакыйгалар, сугыш геройлары белән таныштыру, аны Бөек Ватан сугышындагы җиңү белән чагыштыру, Ватан төшенчәсенең бөеклеген, әлеге җиңүдә татар халкының ролен күрсәтү.

**Катнашалар:** 1 нче алып баручы; 2 нче алып баручы; солдат — совет солдаты киеменнән; кыз һәм егет — татар халык киемнәреннән. Калган укучылар — мәктәп формасыннан.

Укучылар сәхнәдә тезелеп тора, алып баручылар — уртада, бер якка татар егете һәм кызы, икенче якка солдат баса. Монтажның эчтәлеге презентация слайдларында күрсәтелеп барыла.

**1 нче алып баручы.** Хөрмәтле укучылар! 2012 ел Россия Президенты Указы нигезендә «Россия тарихы елы» дип игълан ителде.

**2 нче алып баручы.** Чөнки 2012 ел — юбилейлар елы. Шулар арасында иң зурысы — 1812 елгы Ватан сугышында олы җиңү.

**1 нче алып баручы.** Бу вакыйгага быел 200 ел була.

**2 нче алып баручы.** Ул сугыш та илебезгә күпме кайгы-хәсрәт, күпме күз яше китергән. Күпме сабыйлар ятим калгандыр, бәхеттән мәхрүм булгандыр. Ватанга булган мәхәббәт барысыннан да көчле булып чыккан. Илебезгә Җиңү килгән.

**Солдат.** 1812 елгы Ватан сугышы, нәкъ Бөек Ватан сугышы кебек үк, гадел, милли-азатлык сугышы була. Франция белән Россия арасында тирән сәяси һәм икътисади каршылыклар җитәрлек була.

**1 нче укучы.** Наполеон I нең агрессив сәясәте дөньядагы иң зур ил саналган Россияне яулап алу хыялы белән алып барыла. Моңа 1807 елгы Тильзит солыхы да каршылык күрсәтә алмый.

**2 нче укучы.** Россиягә походка Наполеон бик тырышып әзерләнә. Рус армиясен тиз генә тар-мар итеп, аннан мөмкин кадәр ансат котылырга тели ул. Французлар үзләрен «Бөек армия» дип атый. Наполеон 610 мең кешедән торган гаскәр туплый. Аның гаскәрләрендә, француз солдатларыннан тыш, басып алган илләре: Пруссия, Австрия, Бавария, Саксония, Италия, Польша, Испания солдатлары да була.

**3 нче укучы.** Россия, әлбәттә, йоклап ятмый. Рус хөкүмәте сугыш янавын сизә, сугышны башламый тору чараларын күрә. Илебез дә үзенең гаскәрен арттыру өстендә эшли.

1 нче армия генералы Барклай-де-Толли, 2 нче армия генералы Багратион, 3нче армия генералы Тормасов Александр I гә үзләренең стратегик планнарын тәкъдим итә.

**1 нче алып баручы.** 1812 елның 12 июнендә Наполеон армиясе, сугыш игълан итмичә, Неман елгасы аша Россиягә бәреп керә.

**Солдат.** Әйтерсең, 1941 елда тарих тагын кабатлана. 1941 елның 22 июнендә дә, сугыш игълан итмичә, немец гаскәрләре СССРга бәреп керә.

*(Татар халык җыры — «Ком бураны» башкарыла.)*

**Татар егете.** Халкыбызның «Миңнулла бәете»ндә бу канкойгыч вакыйгалар ачык сурәтләнә.

**Татар кызы.**
Наполеон әйтә икән: «Минем теләгем, —
диеп, —
Башка җирнең җир-сулары —
илгә бүләгем», — диеп.
Французларны кызыктырды
Рәсәйнең маллары;
Шул малларны талар өчен
басып керде яулары.

**2 нче алып баручы.**
Ул елларны ничек онытасың, —
Ил язмышы кылыч өстендә.
Ир-егетләр киткән яу кырына
Алып көче тоеп үзендә.

**4 нче укучы.** Наполеон Смоленскины ала. Мәскәүгә килеп җитә.

**1 нче алып баручы.**
Онытмыйк без Җиңү батырларын,
Алар өчен үлем юк җирдә!..
Буыннардан-буыннарга күчә
Батырларның гомере җыр булып.

Илне яратудан өстен хис юк
Чын батырлык — илгә тугрылык.

**1 нче укучы.** Чит ил басып алучылары белән көрәшкә гаскәр генә түгел, халык ополчениесе дә күтәрелә. Партизаннар сугышы башлана.

**Татар егете.** Партизаннар хәрәкәтен оештыручы, хәрби язучы, танылган шагыйрь, генерал-лейтенант, нәсел шәҗәрәсе белән татарларга барып тоташкан Денис Давыдов була.

**Татар кызы.** Сугыш башлану белән башкалабыз Казан да «кайный» башлый. Татарлар башкаласы качакларны кабул итә, театр артистлары җыелган акчаларын яраланган сугышчыларга ярдәмгә, Ватан ихтыяҗларына тапшыра.

**Татар егете.** Казан университеты профессорлары, студентлары күпләп ополчениегә языла. Казан ополчениесе төзелә. 2977 кешедән торган укчы полк һәм атлылар батальонын берләштергән әлеге ополчение Напалеон армиясенә каршы Германиянең Саксония җирендә Дрезден, Магдебург, Гамбург һ.б. шәһәрләрне азат итешүдә каһарманнарча сугыша.

**Татар кызы.** Казан ополчениесен тәэмин итү өчен губерна халкыннан 346 мең сум хәйрия акчасы җыела. Өстәмә рәвештә казанлылар алтын, көмеш, бакыр һ.б. әйберләр җыеп тапшыра. Ватан сугышы чорында Казан дары заводы һәм постау мануфактурасы продукция җитештерүне нык арттыра.

**Татар егете.** 1812 елгы Ватан сугышында Оренбург, Пенза, Сембер, Сарытау, Касыйм һ.б. төбәкләрдә яшәүче татарлар да актив катнаша, кайберләре югары дәрәҗәле орденнар белән бүләкләнә.

**Татар кызы.** Легендар кавалерист Надежда Дурова Алабуга кызы була. Ул Смоленск янындагы авыр сугышларда шәхси батырлык күрсәтә, Бородино сугышында каты яралана. М.Кутузов аны үзенең ординарецы итеп куя.

**Татар егете.** Татарлар нәселеннән чыккан генерал, сенатор Дмитрий Бибиков та — 1812 елгы Ватан сугышы герое.

**1 нче алып баручы.**
Батырларны барлый-барлый,
Тарих битен актарам.
Ватандашлар батырлыгын
Укып гаҗәпкә калам.

**2 нче алып баручы.**
Илнең азатлыгы өчен
Һәлак булган, кан койган,
Киләчәк буын хакына
Күпме ирләр җан кыйган?

**1 нче алып баручы.**
Ил күгендә ул батырлар
Йолдыз булып яналар,
Ул исемнәр тарихлардан
Мәңгелеккә баралар.

**2 нче укучы.** Басып алучылар белән көрәшкә гади крестьяннар да күтәрелә. Крепостной крестьяннар: «Дошманны куып чыгарсак, безгә ирек бирелер», — дип хыяллана.

**3 нче укучы.** Армия генералы Барклай-де-Толли бик дөрес хәрби хәрәкәтләр ясый, ләкин гаскәренең саны һәм өзерлеге ягыннан руслардан күпкә өстен булган французлар гел алга бара.

**4 нче укучы.** Патша Александр I рус армиясенең башкомандующие итеп генерал Кутузовны билгели. Дошманны Мәскәүгә кертмәс өчен Бородино авылы янында бик көчле сугыш була. Французлар биредә зур югалтуларга дучар ителә. Тәҗрибәле Кутузов, рус армиясен тагын да көчсезләндермәс өчен, икенче көнне сугышны дәвам итми. «Чигенергә!» дигән карар кабул ителә.

**1 нче укучы.** Дәһшәтле Бородино сугышы күренекле рус шагыйре М.Лермонтовның «Бородино» исемле шигырендә бик ачык яктыртылган.

**Татар егете.** Татар-башкорт атлы полклары да Бородино сугышында тиңдәшсез батырлыклар күрсәтә.

**2 нче укучы.** Фили авылындагы Хәрби Совет, армияне саклап калу максаты белән, Мәскәүне вакытлыча калдырып торырга дигән карар кабул итә. Һәм бу — бик дөрес карар була.

**3 нче укучы.** Бушап калган Мәскәүдә көчле янгын башлана. Французлар нишләргә, кем белән сугышырга белми. Ашарлыга бетә, салкын Мәскәү үзәкләренә үтә. Наполеон Александр I не килешү төзергә чакыра.

**1 нче алып баручы.**
Батырлары булган халык
Тарихларда хур булмый,
Иманы камил халыклар
Беркайчан да хур булмый.

**4 нче укучы.** Ләкин Кутузов: «Сугыш башланды гына әле, рус җиреннән французларны бөтенләй куып чыгармый торып, тынычланмаячакбыз», — дип җавап бирә.

**1 нче укучы.** Башкомандующий, французларны чолганышта калдырып, тәмам хәлсезләндерү планын эшли. Россиянең барлык халкы, шул исәптән татарлар да, Наполеонның җиңелмәс армиясе турындагы мифны юкка чыгара. 1812 елның 21 декабрендә француз армиясе Россиядән куып чыгарыла. Патша Александр I 25 декабрьдә (яңа стиль белән 6 гыйнварда) Ватан сугышының тәмамлануы турындагы Манифестка кул куя.

**Солдат.** 1945 елда СССРның барлык халкы, шул исәптән татарлар да, Гитлер Германиясенең җиңелмәс армиясе турындагы мифны юкка чыгара.

**2 нче алып баручы.**
Дуслар өчен — ачык колачыбыз,
Дошман өчен — безнең кылыч нык,

Илем байрагында өч сүз балкый:
Телəктəшлек. Хезмəт. Тынычлык.

**2 нче укучы.** Рус гаскəрлəре бөтен Европаны Наполеон хакимлегеннəн азат итə. 1814 елның 18 маенда Париж солыхы төзелə. Европа Наполеон изүеннəн котыла.

**Татар кызы.** Бишəр йөз сугышчыдан торган 30га якын татар-башкорт атлы полклары Дрезден, Данциг, Берлин, Люксембург, Лейпциг шəһəрлəрен азат итүдə катнаша. Париж өчен сугышларда тиңдəшсез батырлык үрнəклəре күрсəтə.

**Татар егете.**
Французларның иллəре, түгəрəк икəн күллəре;
Французларны куганда үттек без күп иллəрне.

**Татар кызы.**
Французларны кудык без, үз иленə сөрдек без;
Французларны куганда, күп суларны йөздек без.

**Татар егете.**
Наполеонның эшлəпəсе канга тапланган иде;
Без сугышлардан кайтканда иллəр шатланган иде.

**Татар кызы.**
Халкыбыз əлеге дəһшəтле сугыш турында бəетлəр чыгарган. Алдагы юллар «Рус-француз сугышы бəете»ннəн алынды.

**Татар егете.** Тормыш юлы Казаныбыз белəн бəйле рус классик язучысы Лев Николаевич Толстой мəшһүр «Сугыш һəм солых» романында *(китапны күрсəтə)* əлеге канлы вакыйгаларны бөтен тулылыгы белəн сурəтлəде. Əлеге романга нигезлəнеп төшерелгəн кинофильмны да күплəрегезнең караганы бардыр.

**1 нче алып баручы.**
Инде мин ничəнче мəртəбə
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

**2 нче алып баручы.**
Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргə нык басып атладым.
Кешелəр күтəрде Ватанны,
Кешене күтəрде Ватаным.

**1 нче алып баручы.**
Мин күрдем төннəрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибə Ватаным.

**2 нче алып баручы.**
«Сез кайсы халыктан?» — дисəлəр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделəр,
Тик исəн булсын, дип, Ватаным.

*(«Матур булсын» дигəн татар халык җыры башкарыла.)*